КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 29 гыйнвар г.Казань № 56

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 19 июнь, 525 нче, 2015 ел, 15 сентябрь, 666 нчы, 2017 ел, 21 март, 162 нче, 2017 ел, 13 июль, 490 нчы, 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче, 2023 ел, 5 сентябрь, 1076 нчы, 2024 ел, 25 апрель, 276 нчы, 2024 ел, 25 декабрь, 1201 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына,» сүзләрен өстәргә, «Татарстан Республикасының Этил спиртын җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү буенча дәүләт инспекциясе,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе,» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары турындагы нигезләмәгә, 2.17 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«2.17. Дәүләт хезмәтен күрсәтү сыйфатына карата 2.3 пунктының дүртенче – унберенче абзацларында күрсәтелгән таләпләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән очракта, алар дәүләт хезмәте сыйфаты стандартына кертелми.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин